**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының, федераль башкарма хакимият органнары Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы территориясендә коррупциягә каршы чараларны гамәлгә ашыру, шулай ук мониторинг уздыруга вәкаләтле органның коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча башка дәүләт органнары белән мәгълүмати хезмәттәшлеген тәэмин итү буенча эшчәнлеге нәтиҗәлелегенә мониторинг оештыру һәм үткәрү чаралары турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы социаль-икътисади мониторинг комитетының бетерелүе һәм ул башкара торган функцияләрнең Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына тапшырылу белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының, федераль башкарма хакимият органнары Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы территориясендә коррупциягә каршы чараларны гамәлгә ашыру, шулай ук мониторинг уздыруга вәкаләтле органның коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча башка дәүләт органнары белән мәгълүмати хезмәттәшлеген тәэмин итү буенча эшчәнлеге нәтиҗәлелегенә мониторинг оештыру һәм үткәрү чаралары турында» 2011 елның 23 мартындагы ПУ-148 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 4 июнендәге ПУ-523 номерлы һәм 2018 елның 25 августындагы ПУ-586 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Указда:

1 пунктта «Татарстан Республикасы социаль-икътисади мониторинг комитеты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктның өченче абзацында «Татарстан Республикасы социаль-икътисади мониторинг комитеты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктта «Татарстан Республикасы социаль-икътисади мониторинг комитеты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

$5^1$ пунктта «Татарстан Республикасы социаль-икътисади мониторинг комитеты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктта «Татарстан Республикасы социаль-икътисади мониторинг комитеты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

б) Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы территориясендә коррупциягә каршы чараларны гамәлгә ашыру буенча эшчәнлеге нәтиҗәлелегенә мониторинг оештыру һәм үткәрү өчен төп күрсәткечләр исемлегендә:

2 пунктта «биргән» сүзен «бирүче» сүзенә алмаштырырга;

42 пунктта «(аттестация комиссияләре)» сүзләрен төшереп калдырырга;

43 пунктта «(аттестация комиссияләре)» сүзләрен төшереп калдырырга;

44 пунктта «(аттестация комиссияләре тарафыннан)» сүзләрен төшереп калдырырга;

45 пунктта «(аттестация комиссияләре тарафыннан)» сүзләрен төшереп калдырырга;

46 пунктта «(аттестация комиссияләре)» сүзләрен төшереп калдырырга;

54 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«54. Коррупциягә каршы көрәшү темасына укытылган хезмәткәрләр саны, кеше, шул исәптән:

җитәкчеләр;

ярдәмчеләр (киңәшчеләр);

белгечләр;

тәэмин итүче белгечләр.»;

түбәндәге эчтәлекле $54^1$ пунктын өстәргә:

«$54^1$. Коррупциягә каршы көрәшү темасына укытылган, коррупциягә каршы көрәшүдә катнашу эшчәнлек вазыйфаларына кергән хезмәткәрләр саны, кеше, шулардан түбәндәге рәвешләрдә укытылган:

һөнәри яңадан әзерлек бирү;

квалификация күтәрү.»;

57 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«57. Хисап чорында иҗтимагый оешмалар һәм берләшмәләр катнашында коррупциягә каршы көрәшү юнәлешендә уздырылган чаралар (видео-конференция элемтәсен файдаланып уздырылган чараларны да кертеп) саны, берәмлек, шул исәптән түбәндәге рәвешләрдә:».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына үз норматив хокукый актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аның үтәлешен тәэмин итә торган башка карарлар кабул итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2021 ел, 12 апрель
№ ПУ-284